ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«17» мая 2021 ел №131

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный Бор авыл җирлеге генераль планы проектын килештермәү турында бәяләмә әзерләү өчен нигез булган искәрмәләрне җайга салу буенча килештерү комиссиясе төзү турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 16 декабрендәге 411 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, тәңгәлсезлекләрне бетерү һәм аны хокукый анализ һәм мониторинг нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарына һәм норматив хокукый актларга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный Бор авыл җирлеге генераль планы проектын килештермәү турында бәяләмә әзерләү өчен нигез булган искәрмәләрне җайга салу буенча килештерү комиссиясе төзү турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 16 декабрендәге 411 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 4 нче пуктны төшереп калдырырга;
- 5 нче пунктны 4 нче пункт дип санарга;
- 6 нчы пунктны 5 нче пункт дип санарга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**